| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ НАДЕЖДИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>НАДЕЖДИНО АВЫЛ<br>ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Карар**

12.03.2019 ел Надеждино авылы № 3

**“Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, “Җирләү һәм җирләү эше турында”гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, “Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында” Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында”гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, “2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында”гы Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары нигезендә “Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. “Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә беренче һәм икенче номерлы кушымталар нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең бәясен 5946,47 сум күләмендә билгеләргә.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл жирлеге” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Интернет мәгъләмат-телекоммникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урныштырырга: http://nadegd-kaybici.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Надеждино авыл җирлеге башлыгы** **Е.В.Савельева**

Надеждино авыл жирлеге
Башкарма комитетының
2019 ел, 12 март, 3 номерлы
карарына 1 нче кушымта

“Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Надеждино авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәт күрсәтүнең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исемлеге** | **Хезмәт күрсәтү бәясе сумнарда** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Күмү өчен табут һәм башка кирәк-яракларны китереп бирү | 2551,18 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җесәден) алып бару | 682,98 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2712,31 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

Надеждино авыл җирлеге
Башкарма комитетның
2019 ел, 12 март, 3 номерлы
карарына 2 нче кушымта

“Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Надеждино авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәт күрсәтүнең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исемлеге** | **Хезмәт күрсәтү бәясе сумнарда** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетнең гәүдәсен ахирәт киеменә киендерү | 320,72 |
| 3. Күмү өчен табут һәм башка кирәк-яракларны китереп бирү | 2230,46 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җесәден) алып бару | 682,98 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2712,31 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |